Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение

**«Гимназия №1- Центр национального образования»**

Елабужского муниципального района Республики Татарстан

Аслямова Гузель Файзулхаковна
C=RU, OU=МБОУ, O="""Гимназия №1-Центр национального образования"" ЕМР РТ", CN=Аслямова Гузель Файзулхаковна, E=G1.Elb@tatar.ru
Я являюсь автором этого документа

«УТВЕРЖДАЮ»
Директор МБОУ
«Гимназия №1-
Центр национального образования» ЕМР РТ
____________________
Г.Ф. Аслямова
Приказ № 244-шо
от «31» августа 2023г.

Рабочая программа

по учебному курсу «Читаю в поисках смысла»

3 класс

Елабуга 2023

Аңлатма язуы.

Урта (тулы) гомуми белем бирү оешмаларының башлангыч белем бирү этабында “Туган(татар ) телдә аңлап уку” курсының эш программасы предметы Федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгән гомуми белем бирү нәтиҗәләренә куелган таләпләргә туры китерелеп укытыла. “Туган(татар ) телдә аңлап уку” курсының эш программасыннан белем бирүнең сыйфатын арттыру теоретик материалны аңлату барышында, тирән белем бирү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уяту һәм дөрес итеп сөйләшергә, укырга, язарга, фикерләргә өйрәтү таләп ителә.

Туган телдә сөйләшүче сәләтле балалар өчен “Туган(татар ) телдә аңлап уку” курсының эш программасы укучыларда белем алуга һәм фәнгә карата кызыксыну уяту, белемнәрне тирәнәйтү максатын күздә тотып төзелде. Программа сәләтле баланың мөмкинлекләрен тагын да үстерергә, һәр укучының тел белеме буенча сәләтен ачарга ярдәм итәчәк.

**Максат:**

1. Укучыларда коммуникатив компетенция формалаштыру, ягъни сөйләм мөмкинлекләреннән чыгып, туган телдә телдән һәм язмача аралашырга өйрәтү;
2. Балалар әдәбиятын, тарихын, фольклор әсәрләрен өйрәнү аша татар мәдәниятенә карата ихтирам хисләре тәрбияләү.

**Бурыч:**

1. Татарстан Республикасында төрле милләтләр өчен аралашу чарасы буларак татар теле турында мәгълүмат бирү;
2. Сөйләмә һәм язма телне үстерү максаты белән телнең грамматик нигезләрен үзләштерү;
3. Тел материалын үзләштерү барышында, аралашу очракларында, рольле уеннарда укучының шәхси сыйфатларын, игътибарын, фикерләү сәләтен, хәтерен һәм иҗадилыгын үстерү;
4. Предметка карата кызыксыну, уңай мотивация, туган телне өйрәнүгә мөмкинлек бирә торган махсус универсаль уку гамәлләре формалаштыру.

Укучыларның беренче мөстәкыйль ачышлары нәкъ менә башлангыч сыйныфта укыганда күзәтелә.

Хәзерге вакытта башлангыч сыйныф укучылары татар теле буенча мәктәп һәм район буенча гына түгел, республика бәйгеләрендә дә катнашалар. Шуңа күрә балаларны стандарт булмаган биремнәрне үтәүгә хәзерләү, шулай ук чит тирәлектә үзеңне иркен тотарга өйрәтү - түгәрәк эшенең төп бурычларыннан берсе. Эшләрне мөстәкыйль башкару, фәнни – эзләнү эшчәнлеген оештыру иҗади эшчәнлекне башлау өчен мөмкинлек ача.

“Туган(татар ) телдә аңлап уку” курсының эшен оештыруда түбәндәге юнәлешләр күз алдында тотыла:

- сүзгә сак караш тәрбияләү, дөрес сөйләшергә өйрәтү, тел буенча белемнәрне тирәнәйтү, татар халкының мәдәнияты , сәнгате белән тирәнрәк таныштыру, стандарт булмаган биремнәрне үтәү .

Максатка ирешү өчен балада ихтыяр көче тәрбияләргә, бөтен көчен, сәләтен, игътибарын тупларга өйрәтергә кирәк. Шушы сәләтләргә ия булган укучы гына, әти-әни һәм укытучы белән берлектә, зур уңышларга ирешә ала.

Укыту эшчәнлеген башлаганда шушы вакытка укучыларның белем дәрәҗәләрен белү мөһим, бу алга таба эшне ни рәвешле оештыру мөмкинлеген ача. Кайсы эшкә күбрәк вакыт бирүне дөрес планлаштыру, алга таба эшнең нәтиҗәсен арттырырга ярдәм итә.

Түгәрәк эше атнага 1 сәгать исәбеннән планлаштырыла. Еллык сәгать саны - 34.

“Туган(татар ) телдә аңлап уку” **эш программасының максаты һәм бурычлары**

Укучыларның белем дәрәҗәләрен үстерү. Татар телен практик яктан куллануга ирешү.

Бурычлар:

- тел белеме буенча белемнәрне арттыруга ярдәм итү;
- фикерләү сәләтен үстерүгә мөмкинлекләр булдыру;

- үзара зәвыклы итеп аралашуга теләк тудыру һәм Татарстан Республикасы тарихына һәм мәдәниятенә хөрмәт хисе тәбияләү;

**Укытуның шәхескә кагылышлы нәтиҗәләре:**

- укуга карата теләк-омтылыш, җаваплы караш булдыру;
- татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- әйләнә-тирә табигатькә дөрес караш булдыру;
- кешеләр белән аралаша белү культурасы тәрбияләү;
- гаделлек, дөреслек, яхшылык, мәрхәмәтлелек һәм аларның киресе булган сыйфатларны тану, бәяләү;
- алган белем һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәнү.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

Танып-белү нәтиҗәләре:

- әдәби әсәрне дөрес аңлап уку;
- дөрес нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерү;
- үз фикереңне исбатлый һәм яклый алырга күнектерү;
- әсәр хакында дөрес фикер йөртә алу.

Регулятив нәтиҗәләр:

- дәреснең темасын, проблемасын, максатын мөстәкыйль таба белү;
- план буенча эшли белү;
- үз фикерләреңне мөстәкыйль дәлилләү;
- үзанализ һәм үзбәя булдыру.

Коммуникатив нәтиҗәләр:

- иптәшеңне тыңлый, ишетә белү, ишеткәнен үз фикере белән чагыштыру;
- нәтиҗәгә килгәнче, төрле карашларны өйрәнү һәм дөрес юлны сайлау;
- үз фикереңне телдән һәм язма формада башкаларга җиткерә белү;
- килеп чыккан проблемаларны уртага салып хәл итү;
- төркемнәргә берләшү, бер фикергә килә белү;
- өлкәннәр һәм яшьтәшләрең белән продуктив уртак гамәл оештыру;
- текст буенча сораулар бирә белү.

Предмет нәтиҗәләре:

- Укытучының дәрес, уен ситуацияләре белән бәйле сорауларын, күрсәтмәләрен аңлау;
- тыңлаганда, җөмлә, сүз чикләрен билгеләү, интонацияне аеру;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетеп аера белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча укытучының сорауларына җавап бирү һәм сораулар куя белү;
- дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу;
- җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;
- тәкъдим ителгән план, терәк сүзләр ярдәмендә укылган өзек яисә караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү;
- укыган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү;
- үзе, гаиләсе һәм дуслары (мәктәбе, туган җире һ.б.) турында кечкенә информация бирә белү;
- дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
- тексттагы тыныш билгеләренә карата тиешле пауза һәм интонцияләрне үтәү, өтерләр янындагы сүзләрне тиңдәшлек, эндәшү интонцияләре белән уку;
- укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълуматны аерып ала белү;
- кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
- укыганда сүзлекләр куллана белү.

**Тематик план 3 сыйныф**

| № | Тема | Сәгать саны | теория | практика |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Р. Хисмәтуллин «Июль аланы» («Июльская площадь»). | 1 | | |
| 2 | М. Гафури. «Болын» («Луг»). | 1 | | |
| 3 | Н. Дәүли «Бала болыт» («Детское облако») | 1 | | |
| 4 | М. Җәлил. «Яңгыр» («Дождь») | 1 | | |
| 5 | Н. Гыйматдинова. «Казлар» («Гуси »). | 1 | | |
| 6 | Х. Әюп. «Әбиләр чуагы» («Бабье лето»). | 1 | | |
| 7 | Р. Әхмәтҗан. «Соңгы яфрак» («Последний лист»). | 1 | | |
| 8 | Л.Лерон «Хыялый Акбай» («Акбай мечтатель»). | 1 | | |
| 9 | Ә. Габиди «Тере антенналар» («Живые антенны»). | 1 | | |
| 10 | Ф. Садриев «Юкка көттеләр» («Напрасно ждали»). | 1 | | |
| 11 | С.Урайский. «Туган Ил» («Родина»). | 1 | | |
| 12 | Н. Кәримова. «Авылым җыры» («Сельская песня»). | 1 | | |
| 13 | М. Мирза. «Кышның китәсе килми» («»). | 1 | | |
| 14 | Ә. Баян. «Тургай» («Жаворонок»). | 1 | | |
| 15 | К. Насыйри. «Төлке белән әтәч» («Лиса и Петух»). | 1 | | |
| 16 | Г. Тукай. «Яшь агач» («Молодое дерево»). | 1 | | |
| 17 | М. Гафури. «Кәҗә белән Төлке» («Коза и Лиса») | 1 | | |
| 18 | Г. Тукай. «Көзге һәм Маймыл» («Зеркало и Обезьяна»). | 1 | | |
| 19 | Г. Шамуков.«Көзге белән Маймыл» («Зеркало и обезьяна»). | 1 | | |
| 20 | М. Гафури. «Ике Каз белән Бака» («Два Гуся и Лягушка»). | 1 | | |
| 21 | В. Гаршин. «Ил гизүче Бака» («Лягушка путешественница»). | 1 | | |
| 22 | Г. Вәлиева. «Заман әкияте» («Современная сказка»). | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 23 | Л. Лерон. «Сүз тыңлыйсың килмәсә» («»). | 1 | | |
| 24 | Р. Низамова. «Табигатъ күренеше» («»). | 1 | | |
| 25 | Г. Морат. «Үскәч кем булырга?» («»). | 1 | | |
| 26 | Н. Кәримова. «Кое чыпчыгы» («»). | 1 | | |
| 27 | А. Алиш. «Утлы йомырка» («»). | 1 | | |
| 28 | Р. Рәкыйпов. «Мин яратам сине, Татарстан!».(«Я люблю тебя Татарстан!»). | 1 | | |
| 29 | Х. Туфан. «Казан» («Казань»). | 1 | | |
| 30 | З. Гомәрова. «Батырлар хакында» («О героях»). | 1 | | |
| 31 | Р. Харис. «Сугыш турында сөйләшә картлар» («Старики говорят о войне»). | 1 | | |
| 32 | В. Хәйруллина. «Хозурлык һәм горурлык» («Красота и гордость»). | 1 | | |
| 33 | М. Рафиков. «Җир куены» («Земноводные»). | 1 | | |
| 34 | Р. Харис. «Игенче җыры» («Песня земледельца») | 1 | | |
| | Итого | 34 | | |